РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июле 26 номерлы

**«Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24 нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына кертелгән үзгәрешләрне расларга (кушымта).
2. Әлеге карар, 2019 елның 1 октябреннән үз көченә керә торган әлеге карарга кушымтаның 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2019 елның 25 июлендәге
26 номерлы карарына
кушымта

«Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24 нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына
үзгәрешләр

1. 4.2.44. пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Сәнәгать производстволарын, кунакханәләрне торак биналарда урнаштыру, шулай ук торак биналарда миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, «Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш, рөхсәт ителми.
Күпфатирлы йортта торак бина кунакханә хезмәте күрсәтү өчен кулланыла алмый.».

2. 4.2.51 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. 5.1.56. пунктында «СК 2.4.990-00.» сүзләрен «СанКһәмН 2.4.3259-15» сүзләренә алмаштырырга.

4. 5.3.89. пунктында «КК 12-529-03» сүзләрен «Газ бүлү һәм газ куллану челтәрләренең куркынычсызлыгы кагыйдәләре» сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль нормаларны һәм кагыйдәләрне раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 542 номерлы Ростехнадзор боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга.

5. 6.1.7. пунктының 2 җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 4 декабрендәге 201-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә урман фонды җирләрендә гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрен урнаштыру, урман кишәрлекләрен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен, шәхси гараж яки шәхси торак төзелеше өчен бирү тыела.».

6. 6.2.4. пунктында «ГН 2.1.6.1338-03» сүзләрен «ГН 2.1.6.3492-17» сүзләренә алмаштырырга.

7. 7.2.7.3. пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга.

8. 7.3.22, 7.3.23, 7.3.37, 7.3.33, 1-4 кушымтаның 1-4 таблицаларында «(лесопарклар)», «(лесопарклар)» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. Түбән Кама муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларына 1 нче кушымтада:

9.1 «Федераль законнар» бүлегендә:

9.1.1 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон»;

9.1.2 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон»;

9.1.3 41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«41. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон».

9.1.4 42 пунктны төшереп калдырырга.

9.2 «Берләшкән Милләтләр Оешмасының һәм Россия Федерациясенең башка норматив актлары» бүлегендә:

9.2.1 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби объектларының, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм илнең оборона өлкәсендәге бурычларны үтәүче органнарның эшләвен тәэмин итү өчен җирләрне файдалануның аерым шартлары булган тыелган һәм башка зоналарны билгеләү турында» 2014 елның 5 маендагы 405 номерлы РФ Хөкүмәте карары»;

9.2.2 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) саклау зоналары турындагы Нигезләмәне раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2015 елның 12 сентябрендәге 972 номерлы РФ Хөкүмәте карары»;

9.2.3 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан сәүдә объектлары мәйданы белән халыкның минималь тәэмин ителеше нормативларын билгеләү Кагыйдәләрен һәм сәүдә объектлары мәйданы белән халыкның минималь тәэмин ителеше нормативларын исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 24 сентябрендәге 754 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2016 елның 9 апрелендәге 291 номерлы карары»;

9.2.4 13-15 пунктларны төшереп калдырырга;

9.2.5 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» Федераль закон таләпләрен үтәү мәҗбүри нигездә тәэмин ителә торган милли стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмасы (мондый стандартларның һәм җыелма кагыйдәләрнең өлешләре) исемлеген раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1521 номерлы РФ Хөкүмәте карары»;

9.2.6 24 пунктны төшереп калдырырга;

9.2.7 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. «Капиталь төзелеш объектына проект документларын эшләү өчен махсус техник шартларны эшләү һәм килештерү тәртибе турында» 2016 елның 15 апрелендәге 248/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы»;

9.3 «Россия Федерациясенең дәүләт стандартлары (ГОСТ)» бүлегендә:

9.3.1 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Росстандартның «Милли стандартны раслау турында» 2013 елның 17 октябрендәге 1179-ст номерлы боерыгы»;

9.4 «Санитар кагыйдәләр һәм нормалар (СанКһәмН)» бүлегендә:

9.4.1 25 пунктны төшереп калдырырга;

9.4.2 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының эш режимын төзүгә, карап тотуга һәм оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанКһәмН 2.4.4.3172-14 раслау турында» 2014 елның 4 июлендәге 41 номерлы карары»;

9.5 «Санитар кагыйдәләр» бүлегендә:

9.5.1 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. РФ баш дәүләт санитар табибының «Ятим балалар һәм ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эш режимын төзүгә, карап тотуга һәм оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанКһәмН 2.4.3259-15 раслау турында» 2015 елның 9 февралендәге 8 номерлы карары»;

9.5.2 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. РФ баш дәүләт санитар табибының «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда белем бирү һәм тәрбия бирү шартларына һәм оештыруга санитар-эпидемиология таләпләре» СанКһәмН 2.4.2.3286-15 раслау турында» 2015 елның 10 июлендәге 26 номерлы карары»;

9.6 «Гигиена нормалары (ГН)» бүлегендә:

9.6.1 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «Шәһәр һәм авыл җирлекләренең атмосфера һавасында рөхсәт ителгән пычраткыч матдәләрнең чик концентрациясе (рөхсәт ителгән чик концентрациясе)» ГН 2.1.6.3492-17 гигиена нормативларын раслау турында» 2017 елның 22 декабрендәге 165 номерлы карары»;

9.6.2 7-14 пунктларны төшереп калдырырга;

9.7 «Куркынычсызлык кагыйдәләре (КК)» бүлегендә:

9.7.1 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Шартлау-янгын куркынычы булган химик, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү производстволары өчен шартлау куркынычсызлыгының гомуми кагыйдәләре» сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә Федераль нормаларны һәм кагыйдәләрне раслау турында» 2013 елның 11 мартындагы 96 номерлы Ростехнадзор боерыгы»;

9.7.2 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Газ бүлү һәм газ куллану челтәрләренең куркынычсызлыгы кагыйдәләре» сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль нормаларны һәм кагыйдәләрне раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 542 номерлы Ростехнадзор боерыгы»;

9.7.3 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Сыекландырылган углеводород газларыннан файдаланучы объектлар өчен куркынычсызлык кагыйдәләре» сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль нормаларны һәм кагыйдәләрне раслау турында» 2013 елның 21 ноябрендәге 558 номерлы Ростехнадзор боерыгы».

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары — Э.Р. Долотказина